Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы
КАРАРЫ

18 ноябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге территориясендә җирсалымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнеоештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенигезендә

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац белән тулыландырырга:

«гражданнар күмү белән шөгыльләнүче оешмалар, учреждениеләргә карата җир кишәрлекләре»;

1.2. бишенче абзацны алтынчы абзац дипсанарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Бута
авыл җирлеге Башлыгы Д.Е. Абрамов